# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Сарман авыл җирлегенең Яңа Әхмәт авылы торак пунктында
2021 елда үзара салым кертү турында

**2002 елның 13 ноябре** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлегенең Яңа Әхмәт авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2021 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлегенең Яңа Әхмәт авылы җирлек территориясендә ел дәвамында яшәмәүче гражданнардан (студентлар, Кораллы Көчләр сафларында хезмәт итүче затлар), I һәм II төркем инвалидлардан һәм 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнарданнар, хөкем ителгәннәр), тормышта авыр хәлдә калган гаилә әгъзаларыннан (СОП, янгыннан зыян күрүчеләр) тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 350 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

-Яңа Әхмәт авылында вак таштан юлларны төзекләндерү;
- Яңа Әхмәт авылы зиратында йорт төзү өчен материаллар сатып алу;
-Яңа Әхмәт авылы мәдәният йорты өчен музыкаль җиһаз сатып алу;
-Яңа Әхмәт авылында балалар спорт мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру.

3. Әлеге карарны Сарман авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман авылы башкарма комитеты
җитәкчесе
гражданнар җыенында рәислек итүче Н.И.Сахуриев